**Класс**: 6

**Укытучы**: Насыбуллина Резедә Сәйрин кызы

**Программа:** Җәмгыять белеме. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /(Л.Н.Боголюбов һ.б., русчадан Л.Н.Гыймадеева тәрҗемәсе)-Казан: Татар.нәшр., 2020.-160 б.:рәс.б-н.

**Тема**: Кешенең ихтыяҗлары һәм мөмкинлекләре

1 слайд

Ихтыяҗлар нинди була?

Кесә телефоны, компьютер һәм телевизор, самолёт һәм автомобиль…Болар кайчандыр бик сәер, гаҗәеп нәрсәләр булып тоела иде. Алар кулланыла башлаганчы, кеше шулардан башка да яхшы гына яшәгән бит. Әммә күбрәк таралган саен, бу әйберләр үзләренә зуррак яшәү тирәлеген яулап алалар, кешедә аларга ихтияҗ арта, алар көннән-көн күбрәк кирәк була баралар.

2 слайд

Дөнья үзгәрә, кеше ихтыяҗлары да үзгәрә. Кеше тормышта аннан башка көн итеп булмаслык нәрсәдер булуын аңлый. Һәм ул бу кирәкле нәрсәне үзендә булдыру өчен тырыша башлый. Мәсәлән, син яңа фильм турында ишеттең, аны тизрәк карыйсың килә. Син нәрсә эшләрсең? Әти-әниләреңнән шул фильм дискын сатып алуларын сорыйсыңмы?Дусларыңнан алып торасыңмы? Интернаттан файдаланырсыңмы? Кинотеатрга барырсыңмы? Ничек кенә булмасын, кул кушырып утырмаячаксын. Башкача әйтсәк, нәкъ ихтыяҗлар кешене нәрсә дә булса эшләргә этәрә.

3 слайд

Кешегә һава, су, азык-төлек, җылы, йокы, ял кирәк.Ул ничек яшәве һәм үз нәселен калдыру турында кайгырта. Бу-биологик ихтыяҗлар (аларны икенче төрле табигый яки матди ихтыяҗлар дип атыйлар).

4 слайд

Әммә шәхес булу һәм җәмгыятьтә үз урынын табу өчен, кешегә болар гына җитми. Шуңа күрә социаль ихтыяҗлар (аралашуга һәм хезмәткә булган ихтияҗлар) турында да сөйлиләр.Әгәр сәләтләрен чынга ашыра алмаса, тормышта үз урынын тапмаса, кеше бәхетле була алмый.

5 слайд

Кешенең дөньяны танып белүгә, белем һәм күнекмәләр алуга, гармония һәм гүзәллеккә ирешүгә рухи ихтыяҗы бар.

6 слайд

Билгеле бер эшчәнлекне башкаруның уңышлыгы аның ысулларын никадәр тиз, тирән һәм нык үзләштерүдә ачыклана торган сәләтләр (мөмкинлекләр) ярашуыннан тора. Алар кешенең белемнәре һәм осталыкларына гына кайтып калмый.

7 слайд

Сәләтләрне гомуми һәм махсус төрлергә аерып карыйлар.Гомуми сәләтләр (күзәтчелек, күрү һәм эмоциональ хәтер, күзаллау һ.б.) иң күптөрле шөгыльләрдә уңышка ирешергә ярдәм итә. Махсус сәләтләр (математика, сәнгать, музыка, әдәбият, спорт һ.б. буенча) билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешергә булыша.

8 слайд

Кеше теге яки бу эшчәнлек буенча билгеле бер сәләткә ия булып тумый. Нәселдәнлек бары тик сәләт чаткыларын – кешенең потенциаль мөмкинлекләрен генә билгели. Алар сәләтләр үсешенең табигый нигезен тәшкил итә.Сәләт чаткыларына сизү органнарының тумыштан бирелгән кайбер үзенчәлекләрен; нерв системасы үзенчәлекләрен (чыдамлылык, акыл эшчәнлеге шуларга бәйле) кертәләр.

9 слайд

Әгәр кеше бик яхшы сәләт чаткыларына ия булып та, шуңа туры килә торган эшчәнлек белән шөгыльләнмәсә, аның мөмкинлекләре ачылмаячак. Алар шул эшчәнлекне өйрәнү һәм үзләштерү процессында акрынлап формалашачак.

10 слайд

Кешенең эчке дөньясы, аның фикерләре һәм хис-кичерешләре дөньясы ул.Бу дөнья рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерү, ягъни танып белү (белемнәр үзләштерү) процессында формалаша. Һәр кешенең үзенә генә хас рухи дөньясы була. Рухи яктан бай кеше яңа белемнәргә омтыла.

11 слайд

Ничек? Ни өчен? Башкача мөмкин идеме? Сәбәп нәрсәдә?Бу нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкиң? Әлеге сорауларны кеше бигрәк еш кабатлый! Сиңа да, мөгаен, ул сораулар турында уйланырга туры киләдер. Моның кайчан булуын исеңә төшер. Бәлки, өйгә бирелгән эшне үти алмагандадыр? Әллә дәрестә яңа материалны аңлатуларын төшенмәгәндәме? Бәлки, дустың өчен бүләк сайлагандадыр? Ничек кенә булмасын, син хәл итәргә кирәкле мәсьәлә белән очрашкансың.

12 слайд

Әммә аны хәл итү юлын табу җиңел түгел.Мондый хәлләр кешене уйланырга мәҗбүр итә, төрле үй-фикерләр тудыра.”Уй” башка килгән фикер, идея, караш мәгънәсен белдерә. Уйлар -кешенең рухи дөньясының мөһим өлеше ул; уйлый белү – кешегә генә хас үзенчәлекле сыйфат.

13 слайд

Проблема турында уйлану, аны хәл итү юлын табу җиңел эш түгел.Кешенең куйган максатына ирешү теләге никадәр көчлерәк булган саен, әлеге процесс тагын да киеренкерәк була.Уйлаганда, кеше, фикерен туплап, шул уй эчендә кайный.

14 слайд

Ярату һәм шатлану, хөрмәт һәм соклану, нәфрәт, курку...

Кешеләрнең хисләре төрле һәм индивидуаль. Хисләр һәрвакыт кайсыдыр бер предметка юнәлтелә. Аерым гына хөрмәт яки аерым гына ярату булмый. Хисләр кемгәдер (әти-әниләргә, дусларга, укытучыларга) яки нәрсәгәдер (Туган җиргә, яраткан шөгыльгә) мөнәсәбәттә ачыла.

15 слайд

Бер үк төрле вакыйга төрле кешеләрдә төрле хисләр уята. Бу әлеге вакыйганың нәкъ менә шушы кеше өчен никадәр мөһим булуына бәйле.Мәсәлән, китапханә ябылуны китап уку белән кызыксанмаучы кеше белми дә калыр, әммә һәр атна саен кулына яңа китап алырга күнеккән кеше өчен бу күңелсез вакыйга булачак.

16 слайд

Хисләрдән эмоцияләрне аерып карыйлар. Эмоцияләр кешенең теге яки бу мизгелдән кәефен белдерәләр.Кәеф сөенечле яки күңелсез, төшенке яки күтәренке булырга мөмкиң.Ул һәрвакыт теге яки бу сәбәпкә (алган билгегә, дустың белән ачуланышуга, укыган китапка, караган фильмга) бәйле була. Яхшы һәм начар кәеф кешенең үз-үзенең тотышына, вакыйгаларга мөнәсәбәтенә йогынты ясый. Бер үк төрле вакыйганы кеше, кәефенә карап, төрлечә кабул итәргә мөмкиң. Мәсәлән, чынаяк ватылу кебек юк кына нәрсә әниеңдә, аның эш көне ничек узуга карап, төрле кичерешләр, эмоцияләр кузгатыр.

17 слайд

Хисләр уйларга этәрә, уйлар хисләрне кайната, алар кеше гамәлләренә йогынты ясый. Рухи яктан бай кешедә бурыч, гаделлек хисе үскән була.Ул, гаделсезлек күрсә, битараф кала алмый. Хакыйкатькә омтылу, яңаны белү теләге кешене тырышып эшләргә, авырлыкларны җиңәргә этәрә.

**Практик өлеш:**

Җирдә кеше яши. Аның бөтен нәрсәсе дә бар. Ул барысыннан да канәгать, бернәрсә турында хыялланмый, бернәрсәгә дә омтылмый. Ул яши һәм берни дә эшләми. Бу хәл кеше ышанмаслык кебек тоела. Ни өчен? Үзегезнең фикерләрегезне иншада раслагыз.

**Йомгаклау**